КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 17 сентябрь г.Казань № 839

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Даими рәвештә кеше каравына (ярдәменә, күзәтүенә) мохтаҗ булган инвалид балаларга өстәмә айлык акчалата түләү турында» 2012 ел, 7 март, 188 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Даими рәвештә кеше каравына (ярдәменә, күзәтүенә) мохтаҗ булган инвалид балаларга өстәмә айлык акчалата түләү турында» 2012 ел, 7 март, 188 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 29 май, 429 нчы; 2013 ел, 19 гыйнвар, 20 нче; 2013 ел, 12 март, 157 нче; 2013 ел, 31 октябрь, 828 нче; 2015 ел, 29 июль, 550 нче; 2016 ел, 26 декабрь, 997 нче; 2017 ел, 13 июль, 494 нче; 2017 ел, 1 ноябрь, 833 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1 нче пунктта «8 298 сум» сүзләрен «8 941 сум» сүзләренә алыштырырга;

4 нче һәм 4.1 нче пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына әлеге карар белән расланган Нигезләмәне аңлату буенча эш оештырырга.

4.1. Даими рәвештә кеше каравына (ярдәменә, күзәтчелегенә) мохтаҗ булган 18 яшькә кадәрге инвалид балаларга бирелгән (бирелә торган) өстәмә айлык акчалата түләүләр турындагы мәгълүмат «Дәүләт социаль ярдәме турында» 1999 ел, 17 июль, ФЗ-178 нче Федераль закон нигезендә Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырыла дип билгеләргә.»;

әлеге карар белән Даими рәвештә кеше каравына (ярдәменә, күзәтүенә) мохтаҗ булган 18 яшькә кадәрге инвалид балаларга өстәмә айлык акчалата түләү бирү тәртибе турындагы нигезләмәдә:

7 нче һәм 8 нче пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Айлык акчалата түләү билгеләү өчен гариза бирүче яки гариза бирүче тарафыннан Россия Федерациясе законнары нигезендә рәсмиләштерелгән ышанычнамә нигезендә вәкаләтләр бирелгән зат гариза бирүченең яшәү урыны буенча «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесе бүлегенә (алга таба – Үзәк бүлеге) түбәндәге документларны тапшыра:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан расланган форма буенча банкта яки башка кредит оешмасында ачылган шәхси исәп реквизитларын күрсәтеп, айлык акчалата түләү билгеләү турындагы гаризаны (алга таба – гариза) ;

«Татарстан Республикасы буенча Медик-социаль экспертиза баш бюросы» федераль казна учреждениесе (алга таба – медик-социаль экспертиза бюросы) биргән инвалид баланың даими рәвештә кеше каравына (ярдәменә, күзәтүенә) мохтаҗ булуы турында билгеләнгән формадагы белешмә кәгазен яисә инвалид баланың үз-үзенә хезмәт күрсәтү сәләте өченче дәрәҗәдә чикләнгәнлеге хакында билгесе булган индивидуаль тернәкләндерү яки абилитация программасы күчермәсен;

гариза биргән айга кадәр килүче өч ай өчен һәр гаилә әгъзасының керемнәрен раслый торган документларны;

вәкаләтле затлар өчен ышанычнамәне;

алучының гаилә әгъзаларыннан яки аларның законлы вәкилләреннән түбәндәгене (түбәндәгеләрне) раслый торган ирекле рәвештә язылган документны (документларны):

аларның шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә ризалыгы булуны;

гариза бирүченең шәхси мәгълүматларны органга яки оешмага тапшырганда аларның исеменнән эш итәргә вәкаләтен.

Гариза биргәндә гариза бирүче яки ул вәкаләтләр биргән зат паспортын яки шәхесен раслый торган башка документны күрсәтә.

Әгәр документлар күчермәләре Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән тәртиптә расланмаган булса, алар төп нөсхәләре белән бергә бирелә һәм Үзәк бүлеге белгече тарафыннан раслана.

Гаризаны почта аша җибәргәндә аңа теркәлә торган документларның күчермәләре Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән тәртиптә расланган булырга тиеш.

8. Үзәк бүлеге ведомствоара сораулар нигезендә, шул исәптән ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек системасыннан файдаланып, электрон формада айлык акчалата түләү бирү турында карар кабул итү өчен түбәндәге мәгълүматларны соратып ала:

бала тууны (уллыкка (кызлыкка) алуны) дәүләт теркәвенә алу турында;

инвалид балага опека (попечительлек) билгеләү хакында;

инвалид баланы тәрбиягә алган гаиләгә бирү турында;

гариза бирүче белән  аның даими яшәү урыны буенча бергә яшәүче затлар турында;

законлы вәкилнең хезмәткә сәләтле булмаган гражданнарны тәрбияләүне гамәлгә ашыручы затларга билгеләнгән компенсация түләүләрен алуын раслый торган;

халыкны эш белән тәэмин итү дәүләт хезмәте органыннан эшсезлек буенча пособие (стипендия һәм башка түләүләр) алу һәм аларның күләме турында;

Россия Федерациясе Пенсия фонды тарафыннан тормышка ашырыла торган пенсия һәм башка социаль түләүләр алу һәм аларның күләме турында;

Федераль салым хезмәтеннән физик затларның алынган керемнәре турында;

социаль яклау органыннан социаль түләүләр алу һәм аларның күләме турында.

Гариза бирүче яки аның тарафыннан Россия Федерациясе законнары нигезендә рәсмиләштерелгән ышанычнамә нигезендә вәкаләтләр бирелгән зат үз башлангычы белән Үзәк бүлегенә әлеге пунктта күрсәтелгән мәгълүматларны үз эченә алган документларны тапшырырга хокуклы.»;

түбәндәге эчтәлекле $12^1$ нче пункт өстәргә:

«$12^1$. Гариза бирүченең ризалыгы булганда айлык акчалата түләү билгеләү Федераль салым хезмәтендә булган соңгы календарь ел өчен физик затларның керемнәре турындагы мәгълүматлар нигезендә башкарыла.».

2. Бу карар 2020 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин